ГЛАВА ЧЕМОДУРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЗНАКАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Нагорная. д.1а, с. Чемодурово, 423307

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЬ ЧЕМОДУРОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ БАШЛЫГЫ
Нагорная ур., 1а нче йорт,
Чемодурово авылы, 423307

Тел./факс(885592)3-31-61; E-mail:Chmd.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

От 09.11.2020г. №2

2021 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге Чемодурово торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге Уставы белән, карар итәм:

1. 2020 елның 19 ноябрендә 13:00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлегенең Чемодурово торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2020 елның 20 ноябрендә 13:00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово Чемодурово авыл җирлеге торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.

Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге Чемодурово торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенының беренче этабын үткәрү вакыты-2020 елныц 19 ноябрендә 13.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр;
- гражданнар җыенының икенче этабын уздыру вакыты-2019 елның 20 ноябре-13.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр;
- гражданнар җыенының беренче һәм икенче этабын үткәрү урыны-Чемодурово авылы, Нагорная урамы, 3А йорт, Чемодурово авылы Мәдәният йорты залы ;

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

-2020 елның 9 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын түбәндәге адрес буенча бирергә: Чемодурово авылы, Центральная урамы, 4 А йорт, Молодежная урамы, 20А йорт.

- Чемодурово торак пунктында сайлау хокукына ия булган яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- Чемодурово авылы халкына, массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка ысуллар белән халык җыеннары турында хәбәр итәргә.

4. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез, 2021 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар өчен 150 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге Чемодурово торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- бүләк, сувенир продукциясе сатып алу, «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Яңа ел», «Авыл көне» бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү;
- Чемодурово авылы территориясендә үлән чабу, чүп-чар җыю буенча хезмәт күрсәтү;
- Чемодурово авылында юлларны кардан чистарту;
- Чемодурово зираты коймаларын алыштыру
- Чемодурово авылы зиратына контейнер мәйданчыклары урнаштыру, контейнер, киртәләр алу, коймалар ясау һәм урнаштыру, контейнер мәйданчыклары урнаштыру,нигез салу, коймалар кую).

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә:

Чемодурово авылы, Үзәк ур., 4А , Чемодурово авылы, Молодежная ур., 20А,

- Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,
- кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә, Азнакай муниципаль районының рәсми сайты Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

6. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Н.Б.Котельникова